ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**«06» апрель 2020 ел** **№7**

**Наласа авыл җирлеге башкарма комитетының 2014 елның 16 августындагы 13/1 номерлы «2025 нче елга кадәр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча районы прокуратурасы протесты нигезендә, Россия Федерациясенең «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карарына туры китерү максатыннан, Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирде**:

Наласа авыл җирлеге башкарма комитетының 2014 елның 16 августындагы 13/1 номерлы «2025 нче елга кадәр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Су белән тәэмин итү схемасының максатлары һәм бурычлары дигән 1 бүлекнең 28 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Су чыгаруның технологик зонасы - су объектына су чыгару (су объектына су агызу) өчен билгеләнгән бер инженерлык корылмасы аша агызыла торган ташландык суларны агызу (канализация) үзәкләштерелгән системасының бер өлеше, яки су объектына су чыгару өчен технологик яктан бәйләнешле берничә инженерлык корылмасы»;

2) Су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасын үстерүнең максатчан күрсәткечләре дигән9 бүлекнең 1-5 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенең максатчан күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

- суның сыйфаты күрсәткечләре;
- су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәм өзексез булу күрсәткечләре;
- ресурслардан нәтиҗәле файдалану күрсәткечләре, шул исәптән су югалту дәрәҗәсе (кайнар су составында җылылык энергиясен югалту дәрәҗәсе);

- торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән башка күрсәткечләр.»;

3) Су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасын үстерүнең максатчан күрсәткечләре дигән 9 бүлекнең 6 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4) Су чыгаруның үзәкләштерелгән системасын үстерүнең максатчан күрсәткечләре дигән 16 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Су чыгаруның үзәкләштерелгән системасын үстерүнең пландагы күрсәткечләре.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Наласа авыл
җирлеге башлыгы: И.Р.Шакирова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1061688005656 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НАЛАСИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» *
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609009812